РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» апреля 2026 ел г. Альметьевск № 733

Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 апрелендәге 536 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерцияле булмаган оешмага Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2025 елның 25 декабрендәге 2144 номерлы карары нигезендә, Әлмәт муниципаль районы ветераннар (пенсионерлар) Советы рәисе В.И.Яшанинның 2026 елның 10 мартындагы 1282 номерлы мөрәҗәгатен карап,

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 15 апрелендәге 536 номерлы «Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы ветераннарына (пенсионерларына) социаль ярдәм күрсәтү өлкәсендә эшчәнлек алып баручы коммерцияле булмаган оешмага Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында»гы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 сентябрендәге 1360 номерлы, 2022 елның 5 сентябрендәге 1888 номерлы, 2023 елның 22 маендагы 1520 номерлы, 2023 елның 18 сентябрендәге 3310 номерлы, 2024 елның 7 маендагы 1703 номерлы, 2025 елның 20 июнендәге 1470 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. Карар преамбуласында «шулай ук физик затларга - товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүчеләргә» сүзләрен «физик затларга»сүзләренә алмаштырырга.;

1.2. карарга 1 нче кушымтада:

1.2.1. 3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Субсидияләр турындагы мәгълүмат, шул исәптән район бюджеты

заказ № 4553-940

турындагы карарда (район бюджеты турындагы карарга үзгәрешләр кертү турындагы карарда) каралганнары, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләрен бюджет акчаларын төп бүлүчегә җиткергән көннән соң килә торган көннән башлап 10 эш көне эчендә, Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан билгеләнгән тәртиптә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Россия Федерациясе бюджет системасының бердәм порталында (алга таба – бердәм портал) урнаштырыла.»;

1.2.2. 11.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11.1. Субсидия бирү нәтиҗәсе булып район ветераннарының (пенсионерларының) түбәндәге категорияләрен хөрмәтләү тора (билгеләнгән санның кимендә 90 проценты):

а) Бөек Ватан сугышында Җиңү көненә – 480 кеше, шул исәптән Бөек Ватан сугышында катнашучылар-2 кеше;

б) Халыкара өлкәннәр көненә – 717 кеше, шул исәптән Бөек Ватан сугышында катнашучылар-2 кеше, район җирле үзидарә органнары ветераннары (пенсионерлары) – 237 кеше;

в) 90 яшь һәм аннан өлкәнрәк ветераннарның (пенсионерларның) юбилей даталарына – 97 кеше.

Субсидия бирү нәтиҗәләренә субсидия бирелгән елның 31 декабренә кадәр ирешергә кирәк.»

1.2.3. 13 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«13. Субсидия Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә яки кредит оешмаларында субсидия алучыга ачылган счетларга район Башкарма комитеты тарафыннан килешү төзелгән көннән башлап эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә күчерелә.»;

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга, Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А. А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе А.М. Каюмов

РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН МУНИЦИПАЛЬНОЕ ОБРАЗОВАНИЕ «АЛЬМЕТЬЕВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН» • ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ «ӘЛМӘТ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ •
Р06-12061/12
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ АЛЬМЕТЬЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РТ
ИНН 1644035822
КПП 164401001
ОГРН 1051605067172